КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 гыйнвар г.Казань № 25

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тимер юл һәм су транспорты өлкәсендә аерым чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1036 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тимер юл һәм су транспорты өлкәсендә аерым чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1036 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 май, 423 нче; 2022 ел, 29 март, 282 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга тимер юл транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә

урнаштырыла.»;

7 пунктның өченче абзацында «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе) һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Министрлык субсидия алучының субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

25 пунктның икенче абзацында «бюджет акчасын алучы буларак» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $28^1$ пункт өстәргә:

«$28^1$. Субсидия бирүнең нәтиҗәсенә ирешү мониторингын үткәрү, килешү белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә һәм субсидия (контроль нокта) бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле проектны тәмамлау фактын чагылдыра торган вакыйгаларга ирешүдән чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрелә.»;

әлеге карар белән расланган Шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга су транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

7 пунктның өченче абзацында «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен

«10 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе) һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Министрлык субсидия алучының субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

25 пунктның икенче абзацында «бюджет акчасын алучы буларак» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $28^{1}$ пункт өстәргә:

«$28^{1}$. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин